**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 17 мартындагы 820 номерлы карары**

**Мамадыш Тракты урамында Нокса елгасы янындагы территорияне планлаштыру проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 23 гыйнварындагы 190 номерлы «Мамадыш Тракты урамында Нокса елгасы янындагы территорияне планлаштыру проектын әзерләү турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Мамадыш Тракты урамында Нокса елгасы янындагы территорияне планлаштыру проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» (www.docskzn.ru) челтәр басмасында бастырып чыгарырга.

3. Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 17 мартындагы
820 номерлы карары белән
расланды

## Мамадыш Тракты урамында Нокса елгасы янындагы территорияне планлаштыру проекты

Мамадыш Тракты урамында Нокса елгасы янындагы территорияне планлаштыру проекты түбәндәгеләрдән тора:

I. Планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләрен, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зоналары чикләрен күрсәтеп, территорияне планлаштыру сызымы.


II. Кызыл линияләр күрсәтелгән, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге беркетелгән территорияне планлаштыру сызымы.

III. Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмә.

IV. Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә.

Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган документ булып санала һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

I. Чертеж планировки территории с указанием границ существующих и планируемых элементов планировочной структуры, границ зон размещения объектов капитального строительства





## УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

| | |
|---|---|
| | граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки территории |
| | граница элемента планировочной структуры |
| красная линия | действующая красная линия улично-дорожной сети |
| красная линия | устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети |
| красная линия | отменяемая красная линия улично-дорожной сети |
| КЛ ТОП | устанавливаемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети) |
| КЛ ТОП | действующая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети) |
| КЛ ТОП | отменяемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети) |
| | граница отменяемого технического коридора инженерных коммуникаций и сооружений |
| 1 | порядковый номер зоны размещения |
| 1 | вид зоны размещения объектов капитального строительства |
| 3,10 | площадь зоны размещения (га) |
| 2.1.1 | коды видов разрешенного использования |
| 10,78 | максимальная общая площадь жилищного фонда (тыс.кв.м) |
| 10 | максимальная этажность (этажей) |
| н.у. | параметр (характеристика) не устанавливается |
| 5 | планируемая зона размещения объектов общественно-делового назначения |
| 20 | планируемая зона зеленых насаждений общего пользования (часть парка общегородского значения) |
| 21 | существующая зона размещения объектов улично-дорожной сети |
| 19 | существующая зона поверхностных водных объектов |
| | проектируемая блочная комплектная трансформаторная подстанция (ориентировочное расположение) |
| @ | узел агрегации (ориентировочное расположение) |

М 1:2000

## II. Чертеж планировки территории с указанием красных линий




УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

- граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки территории
- действующая красная линия улично-дорожной сети
- устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети
- отменяемая красная линия улично-дорожной сети
- устанавливаемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети)
- действующая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети)
- отменяемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети)
- граница отменяемого технического коридора инженерных коммуникаций и сооружений
- 15 условный номер характерных точек устанавливаемых красных линий

М 1:2000

Документ создан в электронной форме. № 52086-Инф от 13.05.2026. Исполнитель: Переводчики

ЕМСЭД

## III. Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмә.

### 3.1. Проектлаштыру территориясенең урнашу урыны тасвирламасы

Проектлаштыру территориясе Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет районында урнашкан.

Территорияне планлаштыру проектының чикләре булып түбәндәгеләр тора:

- төньяк-көнбатыш ягыннан – М.И.Мәхмүтов исемендәге 184 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

- төньяк-көнчыгыш ягыннан - күпкатлы торак төзелеше («Светлая долина» торак комплексы), парковкалар, административ һәм җитештерү биналары;

- көньяк-көнчыгыш ягыннан – гомуми куллануның яшелләндерелгән территорияләре (шәһәр әһәмиятендәге парк);

- көньяк - көнбатыш ягыннан – гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр (гомумшәһәр әһәмиятендәге парк), инженерлык-техник объектлар (яңгыр канализациясе челтәрен чистарту корылмалары), Кече Клыки торак массивы, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару кишәрлекләре.

Территорияне планлаштыру проекты чикләрендә территориянең мәйданы – 9,26 га.

Проектлана торган территория чикләрендә Казан шәһәр округының Генераль планының табигать-рекреация комплексы картасы нигезендә төп экологик коридорлар (беренче тәртиптә) урнашкан. Проектлана торган территория буйлап Нокса һәм Вертелевка елгалары ага. Территорияне планлаштыру проекты территориясен гомумшәһәр әһәмиятендәге 1 нче класслы өзлексез хәрәкәт магистраль урам – Мамадыш Тракты урамы кисеп үтә.

Территорияне планлаштыру проекты чикләрендә планлаштыру структурасы элементын – гомуми мәйданы 7,12 га булган гомумшәһәр әһәмиятендәге паркның бер өлешен булдыру каралган, бу Казан шәһәр округы генераль планының функциональ зонасына – «гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр зонасына (урман парклары, парклар, бакчалар, скверлар, бульварлар, шәһәр урманнары)»туры килә.

Табигать-рекреация комплексның (алга таба – ПРК) чикләрен үзгәртү аның 1,77 га мәйданлы территориясенең бер өлешен төшереп калдыруны, бер үк вакытта гомуми мәйданы 1,78 га булган җир кишәрлекләрен кертүне күздә

тота. Мондый төзәтмә экологик каркасның өзлексезлеген һәм табигый-рекреация комплексның гомуми мәйданын саклап калуны тәэмин итә.

Табигать-рекреация комплексыннан төшереп калдырыла торган территориядә планлаштыру проектында апостолга тиңләштерелгән Бөек князь Владимир хөрмәтенә рухи-агарту үзәге урнаштыру өчен иҗтимагый-эшлекле зона булдыру каралган (1 номерлы зона).

1 нче таблица

**Территориядән файдалануның проект балансы**

| № т/б | Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары төре | Мәйданы, га | Мәйдан өлеше, % |
|---|---|---|---|
| 1 | Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектлар | 1,42 | 15 |
| 2 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 6,38 | 68 |
| 3 | Җир өсте су объектлары | 0,74 | 8 |
| 4 | Урам-юл челтәре объектлары | 0,86 | 9 |
| **БАРЛЫГЫ** | | **9,4** | **100** |
| | | | |
| **Инженерлык инфраструктурасы** | | **Үлчәү берәмлеге** | **Куәте** |
| Судан файдалану | | куб.м/тәүлек | 18,17 |
| Су чыгару | | куб.м/тәүлек | 12,17 |
| Яңгыр һәм кар сулары | | л/с | 76,5 |
| Электр белән тәэмин итү | | кВт | 186,89 |
| Блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе | | кВА | 2х250 |
| Җылылык белән тәэмин итү | | МВт | 2,13 |

## 3.2. Территорияне төзү параметрлары, торак, җитештерү, иҗтимагый-эшлекле һәм башка билгеләнештәге капиталь төзелеш объектларына характеристика

2 нче таблица

### Территорияне төзү параметрлары, капиталь төзелеш объектларына характеристика

| Территорияне планлаштыру сызымында зона номеры | Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зонасы төре | Урнаштыру зонасы мәйданы, га | Рөхсәт ителгән файдалану төрләре кодлары | Объектларның билгеләнеше | Җир кишәрлекләре мәйданы, кв. м (мин./макс.) | Капиталь төзелеш объектларында катларның максималь саны | Тышкы стеналар габаритларында бинаның катлар буенча суммар мәйданы (мең кв.м) | Бинаның максималь гомуми мәйданы (мең кв. м) | Урнаштырыла торган объектлар турында белешмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Гамәлдәге зоналар | | | | | | | | | |
| 8 | Җир өсте су объектлары | 0,72 | 11.0 3.1.1 | - | Билгеләнмәгән | 0 | 0 | 0 | Нокса елгасы, Вертелевка елгасы |
| 9 | Җир өсте су объектлары | 0,019 | 11.0 3.1.1 | - | Билгеләнмәгән | 0 | 0 | 0 | Вертелевка елгасы |
| 12 | Җир өсте су объектлары | 0,0004 | 11.0 3.1.1 | - | Билгеләнмәгән | 0 | 0 | 0 | Вертелевка елгасы |
| 10 | Урам-юл челтәре | 0,51 | 12.0.1 3.1.1 | Җирле әһәмият-тәге объект | Билгеләнмәгән | 0 | 0 | 0 | Мамадыш Тракты урамы |
| Планлаштырыла торган зоналар | | | | | | | | | |
| 1 | Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге | 1,42 | 3.7 3.4.2 5.2.1 3.1.1 | - | Билгеләнмәгән | 3 | Билгеләнмәгән* | Билгеләнмәгән* | Апостолга тиңләштерелгән Бөек князь Владимир хөрмәтенә рухи-попечительлек үзәге |
| 2 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 0,53 | 3.6.2 12.0.2 5.1.3 3.1.1 | Җирле әһәмиятт әге объект | Билгеләнмәгән | Билгеләнмә-гән | 0 | 0 | Гомумшәһәр әһәмиятендәге паркның бер өлеше |

Документ создан в электронной форме. № 52086-Инф от 13.05.2026. Исполнитель: Переводчики
Страница 13 из 20. Страница создана: 13.05.2026 10:26
ЕМСЭД

| Территорияне планлаштыру сызымында зона номеры | Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зонасы төре | Урнаштыру зонасы мәйданы, га | Рөхсәт ителгән файдалану төрләре кодлары | Объектларның билгеләнеше | Җир кишәрлекләре мәйданы, кв. м (мин./макс.) | Капиталь төзелеш объектларында катларның максималь саны | Тышкы стеналар габаритларында бинаның катлар буенча суммар мәйданы (мең кв.м) | Бинаның максималь гомуми мәйданы (мең кв. м) | Урнаштырыла торган объектлар турында белешмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 2,53 | 3.6.2<br>12.0.2<br>5.1.3<br>3.1.1 | Җирле әһәмиятт әге объект | Билгеләнмә гән | Билгеләнмә-гән | 0 | 0 | |
| 4 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 0,04 | 3.6.2<br>12.0.2<br>5.1.3<br>3.1.1 | Җирле әһәмиятт әге объект | Билгеләнмә гән | Билгеләнмә-гән | 0 | 0 | |
| 5 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 0,0024 | 3.6.2<br>12.0.2<br>5.1.3<br>3.1.1 | Җирле әһәмиятт әге объект | Билгеләнмә гән | Билгеләнмә-гән | 0 | 0 | |
| 6 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 0,82 | 3.6.2<br>12.0.2<br>5.1.3<br>3.1.1 | Җирле әһәмиятт әге объект | Билгеләнмә гән | Билгеләнмә-гән | 0 | 0 | |
| 7 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 2,46 | 3.6.2<br>12.0.2<br>5.1.3<br>3.1.1 | Җирле әһәмиятт әге объект | Билгеләнмә гән | Билгеләнмә-гән | 0 | 0 | |
| 11 | Урам-юл челтәре | 0,35 | 12.0.1<br>3.1.1 | Җирле әһәмиятт әге объект | Билгеләнмә гән | 0 | 0 | 0 | Проектлана торган 1 номерлы юл |

*Әлеге объектларның мәйданнары проектлаштыруның алдагы стадияләрендә төгәлләштерелергә мөмкин.
Кыскартулар исемлеге:
Н.у. – билгеләнмәгән.

## 3.3. Инженерлык һәм коммуналь инфраструктура объектларына характеристика

### 3.3.1. Су белән тәэмин итү

Рухи-попечительлек үзәген су белән тәэмин итүгә тәүлеклек чыгым тәүлегенә 18,17 куб.м тәшкил итә.

«ТеплоГрупп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять хаты нигезендә проектлана торган объектларны Азат Аббасов урамындагы 6 номерлы бина янындагы Ø 315 мм диаметрлы суүткәргечкә тоташтыру күздә тотыла.

Проектта Азат Аббасов урамындагы 6 номерлы бина янында Ø315 мм диаметрлы суүткәргечкә тоташтырып, Ø160 мм диаметрлы су белән тәэмин итү челтәрләре төзү тәкъдим ителә.

Су белән тәэмин итү системасы хуҗалык һәм янгын сүндерү өчен булган ихтыяҗларны берләштереп күздә тотыла.

Проектлана торган су белән тәэмин итү челтәрләренең гомуми озынлыгы 0,20 км тәшкил итәчәк.

Проектлана торган суүткәргеч челтәрләренең күләме – 2,2 м дан 3,0 м га кадәр.

### 3.3.2. Су чыгару. Хуҗалык-көнкүреш канализациясе.

Рухи-попечительлек үзәгендәге агынты суларның тәүлеклек чыгымы тәүлеккә 12,17 куб.м тәшкил итәчәк.

«ТеплоГрупп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять хаты нигезендә проектлана торган территориядән хуҗалык-көнкүреш агынтыларын Азат Аббасов урамындагы 6 номерлы бина янәшәсендәге Ø225 мм диаметрлы канализация торбасына күчерергә тәкъдим ителә.

Проектта 160 мм диаметрлы үзагышлы хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәре Азат Аббасов урамындагы 6 номерлы бина янында - 225 мм диаметрлы ориентир тоташу ноктасына кадәр төзү тәкъдим ителә.

Су чыгаруның проектлана торган челтәрләренең гомуми озынлыгы 0,21 км тәшкил итә.

### 3.3.3. Су чыгару. Яңгыр канализациясе.

Планлаштырыла торган төзелеш территориясеннән исәпләүләр буенча яңгыр сулары тотылу чыгымнары 76,5 л/сек тәшкил итә.

Казан шәһәре Башкарма комитеты Тышкы төзекләндерү комитетының хаты нигезендә, проектлана торган территориядән яңгыр һәм кар суларын «Весна» торак комплексының яңгыр канализациясе челтәренә чыгару каралган.

Проектта Ø 315 мм ябык типтагы яңгыр канализациясе челтәре төзү тәкъдим ителә.

Проектта шулай ук яңгыр канализациясе челтәренең гамәлдәге участокларын Ø 250 мм диаметрлы Ø 315 мм диаметрлыга, Ø 315 мм Ø400 мм диаметрлыга күчереп яңадан салу каралган.

Үзагышлы канализация челтәрләрен салу тирәнлеге – 1,5-2,5 м.

Проектлана торган яңгыр канализациясе челтәрләренең озынлыгы – 0,19 км.

**3.3.4. Җылылык белән тәэмин итү.**

Рухи-попечительлек үзәген җылылык белән тәэмин итүгә исәпләнгән йөкләнеше 2,13 МВт тәшкил итә.

Проектта «Энергоресурс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең гамәлдәге котельныеннан, 225 м озынлыктагы 2 Ø 159 мм җылылык үткәргечләреннән аерым җылылык челтәре салу каралган.

ОДК системасы белән җиһазландырылган, полиэтилен тышчалы пенополиуретаннан торган ике торбалы җылылык челтәрләрен каналсыз салу күздә тотыла.

Җылылык челтәрләренең уртача тирәнлеге – 1,8 м.

**3.3.5. Электр белән тәэмин ителү.**

Исәпләүләр нигезендә проектлана торган территориядә 186,89 кВт электр куллануны тәшкил итә.

«Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан электр белән тәэмин итү челтәрләрен проектлауга бирелгән техник таләпләргә ярашлы рәвештә, планлаштырыла торган территорияне тукландыру үзәге – Константиновка торак массивында 110 кВ подстанция (яңа трансформатор подстанциясе).

Планлаштырылган төзелешне электр белән тәэмин итү өчен 2×250 кВА БКТП блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе төзү күздә тотыла.

Проектта түбәндәге чаралар карала:

- 2×250 кВА блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе төзү;
- 10 кВ кабель линиясен төзү (проектлаштыру чикләрендә – 0,7 км).

Шулай ук проектта кл 10 кВ электр тапшыруның кабель линияләрен урнаштыру өчен технологик коридорлар каралган – 1 м.

Проектлана торган трансформатор подстанциясе тибы һәм җитештерүчәнлек проектлаштыруның киләчәк стадиясендә төгәлләштерелергә тиеш.

**3.3.6. Элемтә челтәрләре.**

Объектларны элемтә хезмәтләренә тоташтыру ноктасы булып тоташтыру җитәрлек буш сыйдырышлы якындагы узелда урнашкан мәгълүмат тапшыру челтәре җиһазлары торачак.

Хезмәтләргә тоташтыру өчен, 10 Гбит/с тизлек белән мәгълүмат тапшыру мөмкинлеге булган мәгълүмат тапшыру системасы җиһазларына порт (портлар) бүлеп бирә.

Мәгълүмат тапшыру хезмәтләренә тоташтыру җепсел-оптик кабель аша башкарыла. Проектта тоташтырыла торган бинадан ерак булмаган урында керү кабель коесын урнаштыру, шулай ук каналларның диаметры 63 мм булган түбән басымлы полиэтилен торбалар кулланып, кабель канализациясе төзү каралган.

Проект буенча агрегация төене (алга таба – АТ) урнаштырыла. 19" телекоммуникация шкафы урнаштырырга кирәк, ул бары тик АТ өчен генә кулланылачак. Аның үлчәмнәрен ВОЛС ахыргы җиһазларын һәм актив җиһазларны (SFP-лы коммутатор, циркүле электр тәэмин итү системасы һ.б.) урнаштыруны исәпкә алып, проект билгели.

Проектлана торган секторны кабельле телевизион тапшырулар (КТВ) хезмәте белән тәэмин итү өчен комплексның торак йортларында урнаштырыла торган телекоммуникация шкафларына кабельле телевизион тапшырулар оптик үзгәрткечләрен урнаштыруны күздә тотарга кирәк.

Проектта шулай ук гомуми озынлыгы 0,17 км булган ике элемтә челтәре линиясен проектлана торган рухи-попечительлек үзәге территориясеннән чыгару каралган.

Тоташу ноктасын, шулай ук элемтә челтәрләрен трассировкалауны проектның алдагы стадияләрен эшләгәндә ачыкларга кирәк.

**3.4. Транспорт инфраструктурасы объектларының характеристикасы**

Хәзерге вакытта проектлаштыру территориясенә транспорт хезмәте күрсәтү гомумшәһәр әһәмиятендәге 1 класслы өзлексез хәрәкәт магистраль урамы – Мамадыш Тракты урамы һәм җирле әһәмияттәге урам – Александр Курынов урамы буенча башкарыла.

Район әһәмиятендәге урам (Азат Аббасов урамы) һәм җирле әһәмияттәге урам (Александр Курынов урамы), шулай ук проектлана торган 1 номерлы юл планлаштырылган иҗтимагый-эшлекле төзелеш һәм гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләрнең магистраль урам – Мамадыш Тракты

урамы белән бәйләнешен тәэмин итә, төп транспорт һәм җәяүлеләр элемтәсен гамәлгә ашыра.

3.1 таблица

**Урам-юл челтәренең техник-икътисади күрсәткечләре**

| № т/б | Урам атамасы | Урамның категориясе | Кызыл линияләрд әге киңлек, м | Озынлык, м | Автомобил ь юлының киңлеге, м | Мәйданы, кв.м |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Мамадыш Тракты урамы | Гомумшәһәр әһәмиятендәге 1 нче класслы өзлексез хәрәкәт итү магистраль урамы | 52,2-57,6 | 78 | 21,6 | 1685 |
| 2 | Проектлана торган 1 номерлы юл | Юл | 9,4-10,0 | 346 | 6,0 | 2076 |

3.2 таблица

**Транспорт чараларын саклау һәм туктап тору урыннарына һәм аларны урнаштыру планлаштырыла торган урыннарга ихтыяж**

| Территорияне планлаштыру сызымында зона номеры | Объект каршындагы стоянкаларда машина урыннарына ихтыяж | Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зоналары чикләрендә урнаштырылырга тиешле машина урыннарының минималь саны | Урнаштырыла торган объектлар турында белешмәләр |
|---|---|---|---|
| Планлаштырыла торган зона | | | |
| 1 | 76* | 79* | Апостолга тиңләштерелгән Бөек князь Владимир хөрмәтенә рухи-попечительлек үзәге |

* Машина урыннарының күрсәтелгән саны проектлаштыруның алдагы стадияләрендә төгәлләштерелергә мөмкин.

## IV. Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә

4 таблица

### Төзелеше I этап кысаларында каралган капиталь төзелеш объектлары исемлеге

| Этап | Территорияне планлаштыру сызымында зона номеры | Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зонасы төре | Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру, ел | Төзелеш, ел | Реконструкция, ел | Территориядә булган объектларны сүтү | Урнаштырыла торган объектлар турында белешмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| I | Башка билгеләнештәге объектлар | | | | | | |
| | 1 | Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге* | 2028 | 2029 | - | - | Апостолга тиңләштерелгән Бөек князь Владимир хөрмәтенә рухи-попечительлек үзәге |
| | Транспорт инфраструктурасы объектлары | | | | | | |
| | 11 | Урам-юл челтәре | 2028 | 2029 | - | - | Проектлана торган 1 номерлы юл |
| | Гомуми файдаланудагы яшелләндерү | | | | | | |
| | 2 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 2038** | 2040** | - | - | Гомумшәһәр әһәмиятендәге паркның бер өлеше |
| | 3 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 2038** | 2040** | - | - | |
| | 4 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 2038** | 2040** | - | - | |

| Этап | Территорияне планлаштыру сызымында зона номеры | Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зонасы төре | Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру, ел | Төзелеш, ел | Реконструкция, ел | Территориядә булган объектларны сүтү | Урнаштырыла торган объектлар турында белешмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 5 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 2038** | 2040** | - | - | |
| | 6 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 2038** | 2040** | - | - | |
| | 7 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 2038** | 2040** | - | - | |
| | Инженерлык инфраструктурасы объектлары | | | | | | |
| | 1 | Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге | 2028 | 2029 | - | - | Трансформатор подстанциясе* |

* Инженерлык челтәрләрен һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын чыгару, демонтажлау, монтажлау эш документациясе нигезендә капиталь төзелеш объектлары белән берлектә эшләнә һәм гамәлгә ашырыла.

**Вакыты дәүләт һәм муниципаль программаларны формалаштырганда аныкланырга мөмкин.